ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БӘЗӘКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ СӘЙТӘК ТОРАК ПУНКТЫНДА
ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ

# КАРАР

20 ноябрь 2024 ел № 3

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 9 ноябрендәге 9 номерлы карары, 2024 елның 20 ноябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе нигезендә: җыенда сайлау хокукына ия катнашучылар исемлегенә 118 граждан кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә катнашучылар саны 73 кеше; тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: ”Риза” - 73 кеше, “каршы” – 0. Бәян ителгәннәр нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пункты гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районының Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк торак пунктында гражданнар җыенын узган дип санарга, җыен нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. «2025 елда Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлегенең Сәйтәк авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә, I-II төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан һәм аларга тиңләштерелгәннәрдән , югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан бер тапкыр түләүне 50% ка киметеп, 500 сум күләмендә, махсус хәрби операциядә катнашучылар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, үзара салым акчаларын кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә сез ризамы" дигән сорау каралды һәм карар кабул ителде.

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту;( Сәйтәк авылындагы юлларны кардан чистарту, вак таш сатып алу, Сәйтәк авылына илтеп җиткерү, тигезләү).

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чаралары белән тәэмин итү (кое һәм янгын гидранты урнаштыру)

3. Әлеге карарны Бәзәкә авыл җирлегенең махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларына урнаштырып халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга http://pravo.tatarstan.ru һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында « Бәзәкә авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга http://mendeleevsk.tatarstan.ru

4.. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Бәзәкә авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Бәзәкә авыл җирлеге башлыгы И.И. Кәшәфетдинов